**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«22» июль 2021 ел № 13/2

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең инициатив проектларны гамәлгә ашыру өчен территориясен, территория өлешен билгеләү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең инициатив проектларны гамәлгә ашыру өчен территориясен, территория өлешен билгеләү тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru.) урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Р.Ф.Адиев

Совет
АЗЬМУШКИНСКОГО
сельского поселения

Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 22 июльнең 13/2 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең инициатив проектларны гамәлгә ашыру өчен территориясен, территория өлешен билгеләү тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең инициатив проектлар гамәлгә ашырылырга мөмкин булган территориясен, территория өлешен (алга таба – территория) раслау процедурасын билгели.

1.2. Әлеге тәртип максатлары өчен муниципаль берәмлек администрациясенә кертелгән инициатив проект – Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә яисә аның өлешендә яшәүчеләр өчен муниципаль берәмлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен яисә муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына хәл итү хокукы бирелгән башка мәсьәләләрне хәл итү буенча өстенлекле әһәмияткә ия чараларны гамәлгә ашыру тәэмин ителә торган, муниципаль берәмлек администрациясенә кертелгән проект (алга таба – инициатив проект).

1.3. Инициатив проектлар гамәлгә ашырылырга мөмкин булган территория «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге (алга таба – авыл җирлеге) Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

1.4. Инициатив проект гамәлгә ашырылырга мөмкин булган территорияне билгеләү турында гариза белән проект инициаторлары мөрәҗәгать итәргә хокуклы:

1) уналты яшькә җиткән һәм авыл җирлеге территориясендә яшәүче уннан да ким булмаган гражданнан торган инициатив төркем;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары.

1.5. Инициатив проектлар авыл җирлеге чикләрендә гражданнарның түбәндәге яшәү территорияләре чикләрендә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә территорияләре чикләрендә;

2) күпфатирлы торак йорт;

3) торак йортлар төркемнәре;

4) торак микрорайон;

5) җирлек булмаган авыл торак пункты.

2. Инициатив проект гамәлгә ашырылырга мөмкин булган территорияне билгеләү турында гаризаны кертү һәм карау тәртибе

2.1. Инициатив проектлар гамәлгә ашырыла торган территорияне билгеләү өчен, проект инициаторы авыл җирлеге Башкарма комитетына, чикләрен тасвирлап, инициатив проектны гамәлгә ашырырга планлаштырылган территорияне билгеләү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

2.2. Инициатив проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территорияне билгеләү турында гаризага проект инициаторлары кул куя.

Проектның инициаторы инициатив төркем булган очракта, гариза инициатив төркемнең барлык әгъзалары тарафыннан фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта), контакт телефоннарын күрсәтеп имзалана.

Әгәр гариза бирүче территориаль иҗтимагый үзидарә органы булган очракта, гариза территориаль иҗтимагый үзидарә органы җитәкчесе яисә вәкиле тарафыннан, фамилиясен, исемен, атасының исемен күрсәтеп (соңгысы – булган очракта) имзалана.

2.3. Проект инициаторы гаризага түбәндәге документларны терки:

1) инициатив проектның кыскача тасвирламасы;

2) авыл җирлеге Башкарма комитетына инициатив проект кертү һәм аны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган территорияне билгеләү турында карар кабул итү хакында инициатив төркем җыелышы беркетмәсе (гражданнар җыелышының территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча беркетмәсе) күчермәсе.

2.4. Авыл җирлеге Башкарма комитеты гариза кергән көннән 15 календарь көн эчендә карар кабул итә:

1) инициатив проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территория чикләрен билгеләү турында;

2) инициатива проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территория чикләрен билгеләүдән баш тарту турында.

2.5. Инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган территория чикләрен билгеләүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) территория авыл җирлеге территориясеннән читкә чыга;

2) сорала торган территория билгеләнгән тәртиптә башка кулланучыларга беркетелгән яисә милектә тора;

3) сорала торган территория чикләрендә башка инициатив проект гамәлгә ашырыла;

4) сорала торган территориядә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре инициатив проект максатларына туры килми;

5) сорала торган территориядә инициатив проектны гамәлгә ашыру федераль яисә региональ, яисә муниципаль закон нормаларына каршы килә.

2.6. Кабул ителгән карар турында ике эш көне эчендә кабул ителгән карарны нигезләп (баш тарткан очракта) проект инициаторына язмача хәбәр ителә.

2.7. Әлеге Тәртиптнең 2.5 пунктында күрсәтелгән очраклар билгеләнгәндә, авыл җирлеге Башкарма комитеты проект инициаторларына инициатив проектны гамәлгә ашыру өчен башка территория тәкъдим итәргә хокуклы.

2.8. Инициатив проектны гамәлгә ашыру өчен сорала торган территорияне билгеләүдән баш тарту, авыл җирлегенең Башкарма комитеты тарафыннан тиешле карарны кабул итү өчен нигез булган каршылыкларны бетерү шарты белән, күрсәтелгән территорияне билгеләү өчен документларны кабат тапшыруга каршылык булып тормый.

## 3. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Авыл җирлеге Башкарма комитетының инициатив проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территорияне билгеләүдән баш тарту турында карарына законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.